**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе турында

Татарстан Республикасы Президенты эшчәнлеген тәэмин итүне камилләштерү максатында һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясында каралган чараларны гамәлгә ашыру тәмамланганга кадәр, **карар бирәм**:

1. «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» һәм «Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе» атамалары тәңгәл килә дип билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе» атамасын Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлегендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләре вазыйфалары атамаларында кулланырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 10 июнь
№ ПУ-413